СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 16 » июль 2021 ел** **№ 25**

**Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә 2015 елның 03 ноябрендәге 7.2 номерлы карары белән расланган җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2021елның 30 апрелендәге 109-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1.« Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә 2015 елның 03 ноябрендәге 7.2 номерлы карары белән расланган җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү шартлары турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү белән бәйле чыгымнарны каплау тәртибен һәм күләмнәрен билгели.».

Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре (алга таба - Хезмәткәрләр) дип муниципаль хезмәткәрләр, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазифаи затлары, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазифалары булмаган вазифалар биләүче хезмәткәрләр, шулай ук Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү һәм аларга хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче затлар аңлашыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров